СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2016 елның «10» ноябреннән** **№ 19-93**

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 29 сентябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 7 статьяның 1 өлешендә «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру» сүзләрен өстәргә;
- «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра» сүзләрен өстәргә;
- 56 статьяның 1 өлешендә «коллегиаль» сүзен төшереп калдырырга;
- 56 статьяның 2 өлешендә «тора» сүзен «барлыкка килә» сүзенә алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен расларга (1 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары белән үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карарын кабул итәргә һәм гавами тыңлауларга чыгарырга.

4. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча 2015 елның 18 мартында сәг. 10.00 дә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы,80 йорт адресы буенча урнашкан Яңа Чишмә муниципаль районы Советының актлар залында ачык тыңлаулар үткәрергә.

Ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе Яңа Чишмә муниципаль районының 2006 елның 23 ноябрендәге 10-81 номерлы карары белән расланган, 2006 елның 29 ноябрендә «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасының 116 номерында басылып чыккан гавами тыңлаулар турындагы Нигезләмә нигезендә башкарыла.

5. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә ачык тыңлаулар үткәрүне, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының күрсәтелгән карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә гавәми тыңлауларда яңгыраган һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышына кертергә.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
Районы Советының
2016 елның «10» ноябреннән
№ 19-93 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе**

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының» Шахмай авыл җирлеге» Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәр
«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Совет урамы, 80 каб. 314 нче номерлы Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесенә язма рәвештә кертелә.

Тәкъдимнәр «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырылган көннән алып, эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар
Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 каб. No 314 шәхсән яки почта аша конвертта «Уставны тикшерү» билгесе белән бирелә.